КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 август г.Казань № 603

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү турында» 2013 ел, 13 июнь, 404 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү турында» 2013 ел, 13 июнь, 404 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 декабрь, 970 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы:

хезмәт ресурслары балансының беренчел фаразын эшли;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2012 ел, 29 февраль, 178н номерлы боерыгы белән расланган Хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү методикасының IV бүлеге нигезендә фаразланган чорда хезмәт ресурсларының балансланганлыгын бәяләү үткәрә;

Татарстан Республикасында фаразланган чорда хезмәт ресурсларының дисбалансы булган очракта Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына аны бетерү вариантларын җибәрә;

агымдагы елның 15 октябреннән дә соңга калмый хезмәт ресурслары балансының беренчел фаразын Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына карап тикшерүгә һәм килештерүгә җибәрә;

агымдагы елның 15 октябреннән дә соңга калмый Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килештерелгән Татарстан Республикасы хезмәт ресурслары балансының беренчел фаразын карап тикшерү өчен фаразны формалаштыруда катнашучы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына җибәрә;

агымдагы елның 1 декабреннән дә соңга калмый, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы хезмәт ресурслары балансының беренчел фаразын эшләп бетерә һәм аны өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килештерә;

агымдагы елның 10 декабреннән дә соңга калмый хезмәт ресурслары балансы фаразын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына җибәрә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында урнаштыра.»;

8 пунктка «эшчәнлекнең ведомство төрләре буенча ИЭТГРК кодлары нигезендә» сүзләрен өстәргә;

8.2 пунктчада «Авыл хуҗалыгы, ау һәм бу өлкәләрдә хезмәтләр күрсәтү» («Кыргый хайваннарны аулау һәм аларны үрчетү, бу өлкәләрдә хезмәт күрсәтүләрне кертеп» икътисадый эшчәнлеге төреннән тыш),» сүзләрен «Үсемлекчелек һәм терлекчелек, ау һәм бу өлкәләрдә тиешле хезмәтләр күрсәтү,» сүзләренә алмаштырырга;

8.4 пунктчада «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү» сүзләрен «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга;

8.5 пунктчада «Элемтә» сүзен «Мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга;

8.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.6. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән берлектә – узган ел, агымдагы ел һәм фаразланган чор өчен «Транспортировка һәм саклау» икътисадый эшчәнлеге төре буенча мәшгуль уртача еллык сан мәгълүматлары;»;

8.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.7. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән берлектә – узган ел, агымдагы ел һәм фаразланган чор өчен «Мәдәният, спорт, ял һәм күңел ачу оештыру өлкәсендә эшчәнлек» икътисадый эшчәнлеге төре буенча мәшгуль уртача еллык сан мәгълүматлары;»;

8.8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.8. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы белән берлектә – узган ел, агымдагы ел һәм фаразланган чор өчен «Кунакханәләр һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре эшчәнлеге» икътисадый эшчәнлеге төре буенча мәшгуль уртача еллык сан мәгълүматлары;»;

8.9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.9. Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы – түбәндәгеләр белән берлектә:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – узган ел, агымдагы ел һәм фаразланган чор өчен «Файдалы казылмалар чыгару» икътисадый эшчәнлеге төре буенча мәшгуль уртача еллык сан мәгълүматлары;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән – узган ел, агымдагы ел һәм фаразланган чор өчен «Эшкәртү производствосы» икътисадый эшчәнлеге төре буенча мәшгуль уртача еллык сан мәгълүматлары;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – узган ел, агымдагы ел һәм фаразланган чор өчен «Электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү, һаваны чистарту» икътисадый эшчәнлеге төре буенча мәшгуль уртача еллык сан мәгълүматлары;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән – узган ел, агымдагы ел һәм фаразланган чор өчен «Күпләп һәм ваклап сату; автотранспорт чараларын, мотоцикллар ремонтлау» икътисадый эшчәнлеге төре буенча мәшгуль уртача еллык сан мәгълүматлары;»;

8.10 пунктчада «Урман хуҗалыгы, урман әзерләү һәм бу өлкәләрдә хезмәтләр күрсәтү» сүзләрен «Урман эше һәм бүтән урман хуҗалыгы эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга;

8.11 пунктчада «Күчемсез мөлкәт белән операцияләр, аренда һәм хезмәтләр күрсәтү» сүзләрен «Күчемсез мөлкәт белән операцияләр буенча эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга;

8.12 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.12. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән берлектә – узган ел, агымдагы ел һәм фаразланган чор өчен «Мәдәният, спорт, ял һәм күңел ачу оештыру» икътисадый эшчәнлеге төре буенча мәшгуль уртача еллык сан мәгълүматлар.»;

11 пунктта «1-һөнәр статистик күзәтү формалары мәгълүматлары (мәгълүмат-статистика ресурсында, «Эш белән тәэмин итү, хезмәт һәм эш хакы» бүлегенең «Икътисадның махсус өлкәләрендә ихтыяҗ фаразын исәпләү өчен башлангыч күрсәткечләр» бүлекчәсендә урнаштырылган),» сүзләрен төшереп калдырырга;

Кагыйдәләргә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү кагыйдәләренә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 август, 603 нче карары редакциясендә)

## Хезмәт ресурслары балансы фаразы

(мең кеше)

| Т\с | Күрсәткеч исеме | Чираттагы ел | План чорының беренче елы | План чорының икенче елы | Белешмә | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | агымдагы ел | хисап елы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| I. | Хезмәт ресурслары саны (1 – 3 юллар суммасы), | | | | | |
| | шул исәптән: | | | | | |
| 1. | эшкә ярклы яшьтәге эшкә яраклы халык | | | | | |
| 2. | чит ил хезмәт мигрантлары | | | | | |
| 3. | эшкә яраклы яшьтән арткан эшләүче гражданнар (3.1 – 3.2 юллар суммасы), | | | | | |
| | шул исәптән: | | | | | |
| 3.1. | эшкә яраклы яшьтән өлкән пенсионерлар | | | | | |
| 3.2. | эшкә яраклы яшьтән яшь үсмерләр | | | | | |
| II. | Хезмәт ресурсларын бүлү | | | | | |
| 4. | Икътисадта мәшгуль кешеләр саны (хәрби хезмәткәрләрдән тыш) | | | | | |
| 5. | Икътисадта мәшгуль булмаган халык саны (5.1 – 5.3 юллар суммасы), | | | | | |
| | шул исәптән: | | | | | |
| 5.1. | эшкә яраклы яшьтәге эшләми укучылар саны | | | | | |
| 5.2. | эш белән тәэмин итү органнарында теркәлгән эшсезләр саны | | | | | |
| 5.3. | эшкә яраклы яшьтәге халыкның икътисадта мәшгуль булмаган башка категорияләре саны, – барлыгы, | | | | | |
| | шул исәптән эшкә урнашуга мохтаҗ эшкә яраклы инвалидлар саны, | | | | | |
| III. | икътисадта мәшгуль кешеләрне ИЭТБРК бүлекләре буенча бүлү | | | | | |
| 6. | үсемлекчелек һәм терлекчелек, ау һәм бу | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | өлкәләрдә тиешле хезмәтләр күрсәтү, урманчылык һәм башка урман хуҗалыгы эшчәнлеге, балыкчылык, балык үрчетү | | | | | |
| 7. | файдалы казылмалар чыгару | | | | | |
| 8. | эшкәртү производствосы | | | | | |
| 9. | электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һаваны чистару | | | | | |
| 10. | төзелеш | | | | | |
| 11. | күпләп һәм ваклап сату; автотранспорт чараларын һәм мотоцикллар ремонтлау | | | | | |
| 12. | транспортировка һәм саклау | | | | | |
| 13. | кунакханә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре эшчәнлеге | | | | | |
| 14. | мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек | | | | | |
| 15. | финанс һәм иминият эшчәнлеге | | | | | |
| 16. | күчемсез мөлкәт белән операцияләр эшчәнлеге | | | | | |
| 17. | һөнәри, фәнни һәм техник эшчәнлек | | | | | |
| 18. | административ эшчәнлек һәм ярдәмче өстәмә чаралар | | | | | |
| 19. | дәүләт идарәсе һәм хәрби иминлекне тәэмин итү; мәҗбүри социаль тәэмин итү | | | | | |
| 20. | мәгариф | | | | | |
| 21. | сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек | | | | | |
| 22. | мәдәният, спорт, ял һәм күңел ачу оештыру өлкәсендә эшчәнлек | | | | | |
| 23. | башка төр хезмәтләр күрсәтү | | | | | |
| 24. | икътисадый эшчәнлекнең башка төрләре | | | | | |